| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.02.2015 № 103

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 25 февралендә теркәлде, № 2679

Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының “Чернобыль һәлакәте
нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында,
сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне
югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга
(хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә
югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә
торган акчалата компенсация
(инвалидлык билгеләмичә) билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау турында”
01.04.2013, № 181 боерыгына
үзгәрешләр кертү хакында

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация (инвалидлык билгеләмичә) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне камилләштерү максатыннан боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация (инвалидлык билгеләмичә) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 01.04.2013, № 181 боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Боерык исемендә, Боерыкның 1 пунктында “Чернобыль һәлакәте” дигән сүзләрне “техноген һәлакәтләр” сүзләренә алмаштырырга;

Боерык белән расланган Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация (инвалидлык билгеләмичә) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) исемендә “Чернобыль һәлакәте” дигән сүзләрне “техноген һәлакәтләр” сүзләренә алмаштырырга;

1 бүлектә:

1.1 пунктчасында “Чернобыль һәлакәте” дигән сүзләрне “техноген һәлакәтләр” сүзләренә алмаштырырга;

1.2 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтүгә мөрәҗәгать итүчеләр (алга таба – гариза бирүче) булып бу Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте алучылар яки аларның законлы вәкилләре (законнарда күздә тотылган очракларда) яисә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә эш итүгә дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар тора.”;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.3. Дәүләт хезмәте, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Татарстан Республикасы Социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Идарә (бүлек)) йөзендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан, дәүләт хезмәте алучының яшәү урынында күрсәтелә.”;

1.3 пунктның 1.3.2 пунктчасында:

“http://mtsz@tatar.ru” сүзләрен “http://mtsz@tatarstan.ru” сүзләренә алмаштырырга;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

“Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында” 15.05.1991, № 1244-1 Россия Федерациясе Законы (алга таба – № 1244-1 РФ Законы) (РСФСРның Халык депутатлары съезды һәм Югары Советы хәбәрләре, 1991, № 21, 699 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“1957 елда “Маяк” җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар чыгарып ташлану нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында” 26.11.1998 № 175-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 175-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1998, № 48, 5850 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Персональ мәгълүматлар турында” 27 июль, 2006 ел, № 152-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 152-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31 (1 өлеш), 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон)

(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 07.05.2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – № 601 Указ) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Чернобыль һәлакәте нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсацияне (инвалидлык билгеләмичә) түләүнең 03.03.2007 № 136 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) (Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары җыентыгы, 2007, № 11, 1327 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Зыянны каплау һәм гражданнарга Россия Федерациясенең “Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында” законы, “1957 елда “Маяк” җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар чыгарып ташлану нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында” Федераль закон һәм “Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында” Федераль закон белән күздә тотылган социаль ярдәм чараларын бирү буенча Россия Федерациясенең чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итүнең 30.08.2005, № 542 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган кагыйдәләре (Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары җыентыгы, 2005, № 36, 3707 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).”;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1.5. Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба –

гариза) төшенчәсе 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктына туры китереп дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата. Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.";

2 бүлектә:

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында:

2.1 пунктында "Чернобыль һәлакәте" дигән сүзләрне "техноген һәлакәтләр" сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы яки шәһәр округындагы Социаль яклау идарәсе (бүлеге)";

2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Компенсация билгеләү гариза һәм бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар теркәлгән көннән башлап сигез эш көне эчендә башкарыла";

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Почта адресы яки аның тарафыннан кредит оешмасында ачылган счет реквизитлары күрсәтелгән гариза (бу Регламентка 1 нче кушымта).

2. Социаль ярдәм чараларына хокук бирүче таныклык күчермәсе.

3. Барлыкка килгән чирләрнең Чернобыль һәлакәте нәтиҗәләре сәбәбенә бәйлелеген билгеләү турында ведомствоара экспертлар советының йомгаклау бәяләмәсе күчермәсе.

4. Федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениесенең хезмәткә сәләтлелекне югалту фактын раслаучы (инвалидлык билгеләмичә) белешмәсе күчермәсе.

Дәүләт хезмәте алучыларның законлы вәкилләре (законнар нигезендә күздә тотылган очракларда) яки дәүләт хезмәте алучылар вәкаләт биргән затлар, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документлар тапшыра.

Гариза бирүче, мөрәҗәгать иткәндә, шәхесен таныклаучы документ күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләрне гариза бирүче тиешле оешмалардан, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә ала.

Документларның күчермәләре Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланмаган очракта, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан раслана.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, гаризага кушып бирелә торган документлар күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) Россия Федерациясе законнарына туры китереп расланган булырга тиеш.";

2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендәге документны тапшырмау.

2. Гариза һәм документларны (документлар күчермәләрен) Идарәгә (бүлеккә) электрон имза белән № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль

закон таләпләренә туры китереп имзаланмаган (расланмаган) электрон документлар рәвешендә тапшыру.

3. Документларда билгеләнгән тәртиптә расланмаган бетерүләр, өстәп язулар, сызылган сүзләр һәм төзәтүләр булу.

4. Гариза бирүченең дәүләт хезмәтен алучының яшәү урынында булмаган Идарәгә (бүлеккә) мөрәҗәгать итүе.";

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| "2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр билгеләнмәгән.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр:<br>дөрес булмаган (дөреслеккә туры килмәгән) мәгълүматлар кергән документлар тапшыру;<br>дәүләт хезмәте алучы булып тормаучы затның яисә аның законлы вәкиленең, яисә дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслаучы документлар нигезендә, дәүләт хезмәте алучының мәнфәгатьләрен яклаучы затның документлар белән мөрәҗәгать итүе. | |

2.15 пунктның "Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"гаризаны һәм документларны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге.";

алтынчы абзацны төшереп калдырырга;

унынчы абзацта "дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан (прецедентлар, шикаятьләр санының Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гомуми санына чагыштырмасы)" дигән сүзләрне "белгечләр тарафыннан" дигән сүзләр белән алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

"гариза бирүчеләрнең Идарә (бүлек) белгечләре белән аралашуы саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар биргәндә, турыдан-туры, ләкин икедән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә, бердән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча)";

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" графасында 2.16 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) Идарәгә (бүлеккә) № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Дәүләт хезмәте (дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне дә кертеп) күпфункцияле үзәк аша күрсәтелми.";

3 бүлектә:

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күпфункцияле үзәкләрдә үтәү үзенчәлекләре”;

3.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Гариза бирүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Идарәгә (бүлеккә) шәхсән үзе, телефоннан, почта аша, электрон почта аша, шул исәптән техник мөмкинлеге булганда, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша һәм (яки) хат белән мөрәҗәгать итә”.;

өченче абзацны “Идарә (бүлек) белгече” сүзләреннән соң “гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән үзе, телефоннан, почта аша, электрон почта аша һәм (яки) Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша,” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Бу пункт билгели торган процедуралар гариза кергән көнне үтәлә.”;

3.3 пунктында:

3.3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Гариза бирүче, бу Регламентның 2.5 пункты нигезендә, Идарәгә (бүлеккә) компенсация билгеләү турында гариза һәм документлар, аңа кушып, документларның күчермәләрен бирә.

Гариза һәм документларның аңа кушып бирелүче, Россия Федерациясе законына туры китереп расланган күчермәләре (шәхесне таныклаучы документ күчермәсеннән гайре) почта аша җибәрелергә мөмкин.

№ 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланган (расланган) гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) электрон документлар рәвешендә җибәрелергә мөмкин.

Почта аша яки электрон документлар рәвешендә тапшырылган гариза һәм документлар (документлар күчермәләре) 3.3 пункт белән күздә тотылган тәртиптә карап тикшерелә.”;

3.3.2 пунктчасында икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“законлы вәкиле сыйфатында гамәл кылучы гариза бирүченең яисә дәүләт хезмәте алучы тарафыннан вәкаләт бирелгән затның вәкаләтләрен тикшерә;”;

дүртенче абзацны “аңа документларын кире кайтара” дигән сүзләрдән соң “документларны кабул итүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

3.3.2 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац белән тулыландырырга:

“Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, электрон имза белән имзаланган (расланган) документлар (документлар күчермәләре) кушып

бирелмәгән очракта, электрон рәвештә бирелгән гариза теркәлми (кабул ителми).";

3.4 пунктында:

дүртенче һәм җиденче абзацларны көчләрен югалткан дип танырга;

сигезенче абзацта "ике" дигән сүзне "биш" дигән сүзгә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.6 пункт өстәргә:

"3.6. Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәкләр аша күрсәтелми.";

4 бүлекнең 4.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гражданнар, аларның берләшмәләре, оешмалары тарафыннан контрольлек итү Идарә (бүлек) эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу, дәүләт хезмәте күрсәтү барышында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге ярдәмендә башкарыла.";

5 бүлектә:

бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Гариза бирүче тарафыннан Үзәкнең дәүләт хезмәте күрсәтүче бүлегенең, шулай ук аның вазыйфаи затларының яки хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерелү";

5.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Идарә (бүлек) җитәкчесенең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаятьләр Министрлыкка бу эш белән шөгыльләнүче министр урынбасары яки министр исеменә бирелә; министр урынбасарының (министрның) карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.";

5.3 пунктның икенче абзацын "почта аша" дигән сүзләрдән соң "күпфункцияле үзәк аша" дигән сүзләр белән, "Министрлык сайты" дигән сүзләрдән соң "(http//mtsz.tatarstan.ru)" дигән сүзләр белән тулыландырырга;

5.8 пунктның соңгы абзацында "бу Регламентның 5.8 пунктында" сүзләрен "бу пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында," дигән сүзләр белән тулыландырырга;

түбәндәге эчтәлекле 5.9 пунктны өстәргә:

"5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат, булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.";

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация (инвалидлык билгеләмичә) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының

______________________________

муниципаль районындагы (шәһәр округындагы)
Идарә (бүлек) начальнигына

___________________________________________________________________________

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Яшәү урыны адресы (паспортындагыча) ____________________________________

(индексны күрсәтеп)______________________________________________________

__________________________________________, тел. _________________________

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация (инвалидлык билгеләмичә) билгеләү турында

ГАРИЗА

_________________20____ ел

1. Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсацияне (инвалидлык билгеләмичә) түбәндәгеләргә туры китереп билгеләвегезне үтенәм:

“Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында” 15.05.1991, № 1244-1 Россия Федерациясе Законы;

“1957 елда “Маяк” җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар чыгарып ташлану нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар

булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында” 26.11.1998 № 175-ФЗ Федераль закон

(кирәклесенең астына сызарга)

______________________________________________________________

**(дәүләт хезмәте алучының ф.и.о.)**

2. Билгеләнгән түләүләрне банк (филиал) учреждениесенең:
№ ___________________________________ лицевой счетына

______________________________________ почта бүлегенә күчерүегезне үтенәм.

Гаризага кушып, түбәндәге документларны (күчермәләрне) һәм белешмәләрне тапшырам:

| № | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

3. Тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге, шулай ук алар кергән документларның чынлыгы өчен җаваплылыкны үз өстемә алам. Түләүләрне туктатуга (үзгәртүгә) сәбәп булырлык шартлар туу турында үз вакытында хәбәр итү йөкләмәсе турындагы нигезләмә белән таныштым.

4. 2006 елның 27 июлендәге “Персональ мәгълүматлар турында” № 152-ФЗ Федераль законга нигезләнеп, бу Гаризада күрсәтелгән шәхси мәгълүматларымны җыюга, эшкәртүгә, шул исәптән автоматлаштырылган эшкәртүгә, саклауга һәм мәгълүмат алмашу системасындагы өченче затларга тапшыруга ризалыгымны бирәм.

5. Мәгълүматны, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) ____________________________________ алырга риза.

(язмача, телефоннан, смс-хәбәр итеп, электрон почта белән)

____________________________________

**(гариза бирүче имзасы)**

______________________________________________________________________

*Өзеп алу сызыгы*

Расписка-хәбәрнамә

Гариза бирүчене теркәү номеры

___ берәмл. ___ биттә гариза һәм документларны кабул итте

____________________________________________________________20____ел

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)”;

Регламентка 2 нче кушымтаның грифында “Чернобыль һәлакәте” сүзләрен “техноген һәлакәтләр” сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация (инвалидлык билгеләмичә) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
3 нче кушымта

Тәкъдим ителә торган форма

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
________________________________
муниципаль районындагы (шәһәр округындагы)
Идарә (бүлек) начальнигына

“____”________________ел            № ___________

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация (инвалидлык билгеләмичә) билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында

Карар

1. Фамилия, исем, атасының исеме ________________________________________

2. Туган елы ____________________________________________________________

3. Яшәү урыны адресы ____________________________________________________

4. Алучының категориясе

5. Компенсацияне түбәндәгеләргә туры китереп билгеләргә:

"Чернобыль АЭСындагы һәлакәт нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында" 15.05.1991, № 1244-1 Россия Федерациясе Законына: ______________ сум ____________ тиен күләмендә
______________ дан _________________га кадәрге чорга;
"1957 елда "Маяк" җитештерү берләшмәсендәге һәлакәт һәм Теча елгасына радиоактив калдыклар чыгарып ташлану нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә дучар булган Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау турында" 26.11.1998 № 175-ФЗ Федераль законга: ______________ сум ____________ тиен күләмендә
______________ дан _________________га кадәрге чорга;

6. Яңадан исәпләү: ______________________________________________________

7. Компенсация сорап мөрәҗәгать итү көне ____________________________________

8. Компенсация билгеләүдән баш тартырга____________________________________

________________________________________________________________________

Социаль яклау Идарәсе (бүлеге)

начальнигы ____________________________

(имза) (тулы имза)

Белгеч ____________________________________

(имза) (тулы имза)";

Регламентка 4 нче кушымтаның грифында һәм текстында "Чернобыль һәлакәте" сүзләрен "техноген һәлакәтләр" сүзләренә алмаштырырга;

Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелеге блок-схемасында "ышанычлы заты аша" дигән сүзләрне төшереп калдырырга, "2 көн" дигән сүзләрне "5 көн" сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка кушымтаны (белешмәне) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация (инвалидлык билгеләмичә) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
кушымта (белешмә)

**Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендәге радиация тәэсире аркасында, сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләтлелекне югалтуга сәбәп булган зыянны каплауга (хезмәткә сәләтлелекне ни дәрәҗәдә югалтуга бәйсез рәвештә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация (инвалидлык билгеләмичә) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында мәгълүматлар**

1. Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Социаль яклау идарәләре (бүлекләре)

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85551) 2-10-86 2-26-39 | 422230, Әгерҗе ш., К.Маркс ур., 8 й. Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85592) 7-25-10 7-14-25 | 423330, Азнакай ш., Болгар ур., 9 й. Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84344) 2-73-68 2-82-75 | 423060, Аксубай ш.т.б., Ленин ур., 8 й. Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85552) 3-11-46 3-12-81 | 423740, Актаныш ав., Юбилей ур., 45 й. Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84341) 2-41-40 2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.б., Казаков ур., 8 й. Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84346) 2-08-90 2-08-91 | 422870, Базарлы Матак ав., Ленин ур., 9 й. Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе | (8553) 32-45-50 | 423452, Әлмәт ш., 8 Март ур., 21а й. Usz.Almet@tatar.ru |

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Апас муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84376)<br>2-11-84<br>2-10-81 | 422350, Апас ав.,<br>Шоссе ур., 5 й.<br>Usz.Apastovo@tatar.ru |
| Арча муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84366)<br>3-13-53<br>3-13-33 | 422000, Арча ш.,<br>Банк ур., 6в й.<br>Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84369)<br>2-16-60<br>2-16-57 | 422750, Олы Әтнә ав.,<br>Октябрь ур., 9 й.<br>Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81 | 423930, Баулы ш.,<br>Җиңү мәйданы, 4 й.<br>usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84368)<br>2-44-78 | 422250, Балтач ав.,<br>Һ.Такташ ур., 3а й.<br>Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85594)<br>4-20-05<br>4-26-64 | 423231, Бөгелмә ш.,<br>Совет ур., 56 й.<br>Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84374)<br>3-32-10<br>3-35-35<br>3-17-03<br>3-55-29 | 422430, Буа ш.,<br>Ленин ур., 52 й.<br>Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84379)<br>2-17-57<br>2-13-01 | 422570, Югары Ослан ав.,<br>Медгородок ур.<br>Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84365)<br>2-32-43 | 422700, Биектау т/ю ст. б.,<br>Профсоюзлар ур., 1а й.<br>Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84375)<br>2-38-07<br>2-31-52 | 422470, Иске Чүпрәле ав., Үзәк ур., 15 й.<br>Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85557)<br>7-51-55<br>7-87-86 | 423600, Алабуга ш.,<br>Спас ур., 3 й.;<br>Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85558)<br>7-10-64<br>3-43-59 | 423520, Зәй ш.,<br>Крупская ур, 6 й.<br>Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Зеленодол муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84371)<br>5-58-80<br>5-79-90 | 420540, Зеленодол ш.,<br>Ленин ур., 25 й.<br>Usz.Zeldol@tatar.ru |

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Кайбыч муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-14-07<br>2-11-13 | 422330, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-45 | 422820, Кама Тамагы ш.т.б., Карл Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.т.б., Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-47-31<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.т.б., Беренче Май ур., 35 й.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>6-02-26 | 423250, Лениногорск ш., Горький ур., 21 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85563)<br>3-12-36 | 422190, Мамадыш ш., Совет ур., 10 й.<br>Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеев муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85549)<br>2-23-00 | 423650, Менделеев ш., Бурмистров ур., 7а й.<br>Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-77<br>3-14-52 | 423700, Минзәлә ш., Ленин ур., 80 й.<br>Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85556)<br>2-57-37 | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й.<br>Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| “Чаллы шәһәре” муниципаль берәмлегендәге Социаль яклау идарәсе | (8552)<br>34-48-48<br>58-71-52 | 423805, Чаллы ш., проспект Х.Туфана, д. 23<br>Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районындагы Социаль яклау идарәсе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-89 | 423570, Түбән Кама ш., Тынычлык пр., 60 й.<br>usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84348)<br>2-20-15 | 423190, Яңа Чишмә ав., Совет ур., 80 й.<br>Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-55<br>2-39-88 | 423042, Нурлат ш., Мәктәп ур., 8 й.<br>Usz.Nurlat@tatar.ru |

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Питрәч муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84367)<br>3-06-68<br>3-06-72 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й.<br>Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | 422650, Балык Бистәсе ав.,<br>Завод ур., 6а й.<br>Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84362)<br>2-34-37 | 422060, Байлар Сабасы ав.,<br>Тукай ур., 87 й.<br>Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85559)<br>2-45-72<br>2-49-87 | 423350, Сарман ав.,<br>Куйбышев ур., 36 й.<br>Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84347)<br>3-08-81<br>3-00-00<br>3-08-98 | 422864, Болгар ш.,<br>Хирург Шеронов ур., 13 й.<br>Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84373)<br>2-62-31 | 422370, Тәтеш ш.,<br>Ленин ур., 114 й.<br>Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (8552)<br>70-00-57 | 423807, Чаллы ш.,<br>М.Җәлил проспекты, 46 й.<br>Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84360)<br>2-13-41 | 422080, Теләче ав.,<br>Большая Нагорная ур., 5 й.<br>Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84396)<br>2-57-05<br>2-50-94 | 423100, Чирмешән ав.,<br>Гагарин ур, 7 й.<br>Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (84342)<br>5-55-73<br>5-11-50 | 422980, Чистай ш.,<br>Урицкий ур., 45 й.<br>Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районындагы Социаль яклау бүлеге | (85593)<br>2-21-43<br>2-82-91<br>2-84-41 | 423950, Урыссу ш.т.б.,<br>Пушкин ур., 105/1 й.<br>Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Авиатөзелеш районындагы Социаль яклау бүлеге | 571-58-00 | 420036, Казан ш.,<br>Тимирязев ур., 8 й.<br>Usz.Avia@tatar.ru |

| Идарә (бүлек) атамасы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Вахитов районындагы Социаль яклау бүлеге | 238-10-55 | 420197, Казан ш., Вишневский ур., 10 й. Usz.Vahit@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Киров районындагы Социаль яклау бүлеге | 554-47-80 | 420102, Казан ш., Галимҗан Баруди ур., 5 й.; Usz. Kirov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Мәскәү районындагы Социаль яклау бүлеге | 544-89-94 | 420095, Казан ш., Блюхер ур., 81а й. Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Яңа Савин районындагы Социаль яклау бүлеге | 523-75-82 | 420124, Казан ш., Хөсәен Ямашев проспекты, 37 й. Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Идел буе районындагы Социаль яклау бүлеге | 224-04-20 | 420110, Казан ш., Рихард Зорге ур., 39 й. Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районындагы Социаль яклау бүлеге | 273-18-06 | 420073, Казан ш., Гадел Кутуй ур., 33 й.; Usz.SovOR@tatar.ru |

## 2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-02 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Bytaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чаралары методологиясе бүлеге начальнигы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Күрсәтелүче социаль ярдәм чараларының функциональ аудиты бүлеге начальнигы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе начальнигы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru |

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**